КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 28 гыйнвар г.Казань № 39

Тукай муниципаль районында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Җирләрне яки җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында» 2004 елның 21 декабрендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьядагы 1 өлешенең 4 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Тукай муниципаль районында урнашкан дәүләт милкендә булган 0,9 гектар гомуми мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлеген 16:39:012101:124 кадастр саны белән юл сервисы объектларын урнаштыру максатларында сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшыру, телевидение, мәгълүмат, космик эшчәнлекне тәэмин итү җирләре, оборона җирләре, куркынычсызлыз һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин